ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елгы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисап хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елгы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан тәкъдим ителгән хисапны «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә карап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елгы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисапны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елгы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисап буенча фикер алышу барышында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутат берләшмәләре вәкилләре, депутатлары тарафыннан әйтелгән тәкъдимнәрне карау һәм кирәкле чаралар күрү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. 2024 елның 29 февралендә Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Юлламасында, 2024 елга Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасында, гамәлдәге илкүләм проектларда, дәүләт программаларында билгеләнгән төп нигезләмәләрне һәм бурычларны гамәлгә ашыруда дәүләт органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген алга таба арттыруны тәэмин итәргә.

3.2. Җәмәгатьчелек фикерен мониторинглау, 2024 елга Гавами өстенлекләр реестрында билгеләнгән чараларны, аларны гамәлдәге һәм эшләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт программаларына кертүне тәэмин итеп, гамәлгә ашыру эшен дәвам итәргә.

3.3. Татарстан Республикасы гавами хакимият органнары белән хезмәттәшлектә Татарстан Республикасының социаль-икътисадый тотрыклылыгын тәэмин итү һәм икътисадның барлык тармакларының ныклыгын арттыру буенча комплекслы чараларны гамәлгә ашыруны дәвам итәргә.

3.4. Эшче һөнәрләрнең абруен арттыру эшен яхшыртырга, шул исәптән квалификацияле кадрларга ярдәм һәм аларны җәлеп итүне кызыксындыру чараларын эшләү юлы белән.

3.5. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм чараларын гамәлгә ашыру эшен дәвам итәргә.

3.6. Салым түләүчеләргә административ басымны киметү, салымнар түләү өчен уңайлы шартлар булдыру һәм салымнар җыюны арттыру эшен дәвам итәргә.

3.7. Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән хезмәттәшлектә хуҗалык итү субъектларының түләү мөмкинлеген анализлау, аларның банкротлыгын кисәтү эшен дәвам итәргә.

3.8. Республиканың дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмалары объектларының (территорияләренең), шулай ук барлык милек рәвешендәге мөһим предприятиеләрнең һәм оешмаларның террордан сакланышын көчәйтү буенча комплекслы чаралар күрергә.

3.9. «Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясындагы беренче өлешенең дәүләт ярдәмен Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслау өлешендә гамәлдә булуын кире кайтару мәсьәләсен карарга.

3.10. Авылда эшлекле активлыкны үстерү, шәхси ярдәмче хуҗалыклар үсешенә ярдәм итү эшен активлаштырырга, ветеринария һәм фитосанитария иминлеге мәсьәләләренә аеруча игътибар бирергә.

3.11. Җирле инициативаларга ярдәм итү һәм халыкның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне чишүдә катнашу механизмы буларак, инициатив проектларны кертүгә һәм үстерүгә ярдәм итәргә.

3.12. 2024 елда БРИКС берләшмәсендә Россия Федерациясе рәислеге кысаларында Казан шәһәрендә төп халыкара чараларны үткәрүгә җирле үзидарә органнары, граждан җәмгыяте институтлары белән берлектә, федераль башкарма хакимият органнары белән хезмәттәшлектә кирәк булган оештыру ярдәме, мәгълүмати, методик ярдәм күрсәтергә.

3.13. Татарстан Республикасы законнарында каралган норматив хокукый актларны үз вакытында кабул итүне тәэмин итәргә.

3.14. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елгы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисапны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына норматив хокукый базаны камилләштерү өлешендә һәрьяклап булышлык күрсәтергә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 19 апреле
№ 2429-VI ДС